**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**КАРАР**

“13” нче декабрь 2018 нче ел № 584

**«Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә, Архангельск һәм Зирекле авыл җирлекләре чикләрендә урнашкан «Архангельск котельная» линия объектына территорияне планлаштыру проекты һәм межалау проекты өчен Карар кабул итү турында»**

Территорияне шәһәр төзелеше документлары белән тәэмин итү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 46 маддәсе, 2003 нче елның 6 нчы октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФК номерлы Федераль канунның 14, 15 маддәләре нигезендә, гавами тыңлаулар беркетмәсен һәм гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча Бәяләмәне исәпкә алып, **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Яңа Чишмә һәм Архангельск һәм Зирекле авыл җирлекләре чикләрендә урнашкан «Архангельск котельная» - В.Д.Шашин исемендәге “Татнефть” ГАҖ объекты проектлау һәм төзү өчен территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне межалау проекты составында территорияне планлаштыру буенча әзерләнгән документацияне расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә йөклим.

**Башкарма комитет җитәкчесе**
**Яңа Чишмә муниципаль районы** **Р.Р. Фәсахов**